СОВЕТ НОВОАКСУБАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АКСУБАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА АКСУБАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**КАРАР**

№ 84 24.05.2024 ел.

**Җирле салымнар суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты , Россия Федерациясе Федераль салым хезмәтенең 19.08.2010 № ЯК-7-8/393 боерыгы “Түләнүгә өметсез дип танылган пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча недоимканы, пенялар, штрафлар һәм процентлар буенча бурычларны түләп бетерүне ышанычсыз дип тану шартларын раслаучы документлар исемлеге”нигезендә Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Аксубай авыл җирлеге Советы карар итә:
1. Җирле салымнар суммасы (алга таба бурыч)буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләргә:

- варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;
2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;
- Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларда 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.

2. Салым түләүченең бурычын исәптән чыгару салым органы тарафыннан әлеге карар һәм җирле салымнар суммалары буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар нигезендә башкарыла:
1) әлеге карарның 1.1 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:
а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;
б) үлем белән бәйле рәвештә салым органнарында физик затны исәптән төшерү турында мәгълүмат;
в) мирас хокукы турында таныклык бирү турында мәгълүмат булмау турында салым органы белешмәсе;
2) әлеге карарның 1.2 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:
а) оешманың, шәхси эшмәкәрнең, шәхси эшмәкәр статусын югалткан физик затның исәпкә алу урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;
б) салым гамәлдән чыгарылган норматив хокукый акт(исеме, датасы, номеры) турында мәгълүмат;
3) әлеге карарның 1.3 пунктында күрсәтелгән нигез булганда, салым органының 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу турында белешмәсе.

3. 26.02.2021 елгы 18 номерлы «бурычларны, пенялар буенча бурычларны һәм җирле салымнар буенча штрафларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында»карарны үз көчен югалткан дип танырга

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://aksubayevo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Яңа Аксубай авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе А.В.Макаров